ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

04.07.2022 ел — Баулы шәһәре — № 125

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы карарына (2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы, 2020 елның 28 апрелендәге 90 номерлы, 2020 елның 25 маендагы 118 номерлы 2021 елның 2 нобярендәге 195 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 245 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

В соответствии с постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 15.06.2022 №566 «О внесении изменений в отдельные постановления Кабинета Министров Республики Татарстан» Исполнительный комитет Бавлинского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 566 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы карарына (2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы, 2020 елның 28 апрелендәге 90 номерлы, 2020 елның 25 маендагы 118 номерлы 2021 елның 2 нобярендәге 195 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 245 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 1 нче кушымта):

VI «стимуллаштыручы характердагы түләүләр» бүлегендә 6.14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.14.3. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII бүлектә «Оешма җитәкчесенең, оешма җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе» бүлегендә:

8.5. пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыргыч характердагы түләүләр гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.»;

8.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыргыч характердагы түләүләр, гомуми белем бирү оешмасының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыргыч характердагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүнең иң чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.»;

Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 2 нче кушымта):

V «стимуллаштыручы характердагы түләүләр» бүлегендә 5.13.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.14.3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек

нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VII “Оешма җитәкчесенең, оешма җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе” бүлегендә:

7.5. пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыргыч характердагы түләүләр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә стимул характерындагы түләүләр ел йомгаклары буенча мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен ай саен гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

7.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыргыч характердагы түләүләр, мәктәпкәчә белем бирү оешмасының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыргыч характердагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүнең иң чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.»;

Баулы муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә (күрсәтелгән карарга 3 нче кушымта):

VI «стимуллаштыручы характердагы түләүләр» бүлегендә 6.6.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6.3. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген күтәрү һәм Россия Федерациясе Президентының «2012-2017 елларга

балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең милли стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы белән билгеләнгән һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча, акча булганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме күрсәтелгән максатларда өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.»;

VIII «Оешма җитәкчесенең, оешма җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе» бүлегендә:

8.5. пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.5. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул характерын түләү, эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.»;

8.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.6. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыргыч характердагы түләүләр, эшчәнлекләренең локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыргыч характердагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе өстәмә белем бирү мәгариф оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров